**ИСПОЛКОМ АПАСТОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422350, пгт. Апастово, улица Советская, д.2

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422350, штп. Апас, Советская урамы, 2 йорт

тел.: (84376) 2-13-52, факс: 2-19-27, e-mail: apast@tatar.ru, http://apastovo.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№ 128 от 07.06.2023

**Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 15 ноябрендәге 360 номерлы карары белән расланган бинаны торак бина дип, торак бинаны яшәү өчен яраксы һәм күпфатирлы йортны авария хәлендгеә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тану буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 28 гыйнварындагы 47 номерлы “Бинаны торак бина дип, торак бинаны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендәге һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тану турындагы нигезләмәне раслау хакында» карарына ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Башкарма комитеты карар итте:

1.Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 15 ноябрендәге 360 номерлы карары белән расланган бинаны торак бина дип, торак бинаны яшәү өчен яраксы һәм күпфатирлы йортны авария хәлендгеә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тану буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.5 бүлегенең 1.5.1 пунктындагы җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“күпфатирлы йорт - Россия Федерациясе Торак кодексының 15 статьясының 6 өлешендә билгеләнгән билгеләргә туры килгән бина;”;

1.2.2.3 бүлегенң 2.3.1 пунктындагы 1 пунктчасын “шулай ук күпфатирлы йортны авария хәлендәге һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле” сүзләр белән тулыландырырга;

1.3. 3 нче номерлы кушымтада гариза исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Бинаны торак бина дип, торак бинаны яшәү өчен яраксыз һәм (яки)күпфатирлы йортны авария хәлендәге һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тану турында гариза»;

1.4. 3 нче номерлы кушымтаның өченчк абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 28 гыйнварындагы 47 номерлы “Бинаны торак бина дип, торак бинаны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендәге һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тану турындагы нигезләмәне раслау хакында» нигезендә .

«На основании постановления Правительства Российской Федерации от 28 января 2006 г. № 47 «Об утверждении Положения о признании помещения жилым помещением, жилого помещения непригодным для проживания и многоквартирного дома аварийным и подлежащим сносу или реконструкции» түбәндәге нигезләр белән бәйле рәвештә бинаны торак бина яки торак бинаны яшәү өчен яраксыз һәм (яки) күп фатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тануны сорыйм”.

2..Әлеге карарны “Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматның рәсми порталы» (pravo.tatarstan.ru) интернет–ресурсында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә (apastovo.tatarstan.ru).

3.Бу карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары А.М. Хәсәновка йөкләргә.

**Җитәкче вазыйфаларын**
**башкаручы** **Б.Н. Әхмәтҗанов**